**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге Төрнәс авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ**

«02» ноябрь 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Төрнәс авыл җирлеге Төрнәс авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

2025 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Төрнәс авыл җирлегенең Төрнәс авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1нче төркем инвалидлардан, балачактан инвалид булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- Төрнәс торак пунктында урамнарны яктырту җайланмасы;
- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Төрнәс т. п. юлларын салу, сезонлы карап тоту);
- Су белән тәэмин итү системаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау һәм су чыгару, су җыю манаралары, скважиналар һәм башка инженерлык чишмәләрдән су алуны тәэмин итүче корылмалар су белән тәэмин итү, аны чистарту, транспортировкалау һәм халыкка су бирү Төрнәс торак пунктында (скважиналарны лицензияләү);
- Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү ( янгын гидрантлары);
- Трактор өчен тагылмалы җайланмалар сатып алу;
- Төрнәс т. п. территориясен (бакча, мәктәп, үзәк урамнары) төзекләндерү.
- Төрнәс т. п. урамнарындагы агачларны җыештыру.

Халык җыенында рәислек итүче: С.В. Белов

Төрнәс авыл җирлеге башлыгы С.В.Белов